**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 ноябрь № 869

г. Казань

2016 елга балалар ризыгының махсус сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны балалар ризыгының махсус сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итүгә норматив чыгымнарны;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны балалар ризыгының махсус сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итүгә хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативларын.

2. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе белән берлектә, туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын алучы өч яшькә кадәрге балаларны балаларның категорияләре, яшьләре һәм алына торган продукция төрләре буенча аерым исәпкә алуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 26 сентябрь, 683 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\869.docx.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 18 ноябрь, 869 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны балалар ризыгының махсус сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итүгә норматив чыгымнар

(көнгә сум)

| Балалар ризыгының махсус сөт продуктларын алучылар категориясе | Түбәндәге яшьтәге балаларга норматив чыгымнар | | |
|---|---|---|---|
| | 0 айдан 6 айга кадәр | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр |
| Җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар;<br>балалар ризыгының махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | 18,44 | 38,56 | 26,81 |

F:\KARAR\2015\869.docx.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 18 ноябрь, 869 нчы
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны балалар ризыгының махсус сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итүгә хезмәтләр күрсәтү күләмнәре

| Балалар ризыгының махсус сөт продуктлары алучылар категориясе | Балаларның яше | Елга хезмәт күрсәтүләр саны, бала-көн | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | адаптацияләнгән сыек сөт катнашмасы | сөт | кефир | эремчек |
| Җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар; балалар ризыгының махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 909 144 | - | - | - |
| | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 3 106 974 | 3 106 974 | 3 106 974 | 3 106 974 |
| | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр | - | 10 966 458 | 10 966 458 | 10 966 458 |